**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

21.04.2015 ел Яр Чаллы № 1713

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2014 елның 14 апрелендәге 1495 номерлы карарыүз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 23.06.2014 ел, №171-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 12.02.20l 5 № 1 боерыгы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Тукай муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»14.04.2014 № 1495 карарының үз көчен югалтуын танырга.
2. Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына юридик бүлек белән берлектә Тукай муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләүне тәкъдим итәргә.
3. Тукай районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә тапшырылган вәкаләтләр нигезендә җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев